**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 253**
**17.06.2019**

Шәһәр Хакименең 2015 елның 31 декабрендәге М 415 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2015 елның 31 декабрендәге М 415 нче карары белән (шәһәр Хакименең 2017 елның 12 декабрендәге М 483 нче карары редакциясендә) расланган «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү турында нигезнамәгә, 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7. Пенсия яшенә җиткәннән соң һәм шәхси гариза бирелгән көннән башлап, «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә лаек булган затларга Башкарма комитет тарафыннан шәһәр бюджеты акчалары хисабына ай саен 1 149 сум күләмендә акчалата түләү башкарыла. Ай саен бирелә торган акчалата түләү гаилә әгъзаларына кагылмый.».

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев